# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 1** **23.11.2019ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге составына керүче
Әлкәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2020 елда, Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әлкәй авылында бәйрәмнәр уздыру "Җиңү көне", "Сабантуй", "Өлкәннәр көне", "Яңа ел", "Инвалидлар көне";
- Әлкәй авылында янгын ранецлары сатып алу;
- Әлкәй авылында юлларын кардан чистарту;
- җәйге чорда Әлкәй авылында территорияләрне чабу;
- Әлкәй авылы Урак һәм Чүкеч урамы юлына вак таш(щебенка) җәю(сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әлкәй авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен төзекләндерү(чәчәк үсентеләре сатып алу);
- Әлкәй авылында эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү;
- Әлкәй авылында зиратларга дератизация уздыру.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 379 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 216 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 216 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге составына керүче Әлкәй авылыдна узган халык җыенын , халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2020 елда, Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан

сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әлкәй авылында бәйрәмнәр уздыру "Җиңү көне", "Сабантуй", "Өлкәннәр көне", "Яңа ел", "Инвалидлар көне";
- Әлкәй авылында янгын ранецлары сатып алу;
- Әлкәй авылында юлларын кардан чистарту;
- җәйге чорда Әлкәй авылында территорияләрне чабу;
- Әлкәй авылы Урак һәм Чүкеч урамы юлына вак таш(щебенка) җәю(сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әлкәй авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен төзекләндерү(чәчәк үсентеләре сатып алу);
- Әлкәй авылында эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү;
- Әлкәй авылында зиратларга дератизация уздыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әлкәй авылы, Пер.Совет ур.,44а йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлкәй авыл җирлеге Башлыгы С.З.Зиннурова

АЛЬКЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002494
КПП 164301001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ